РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

с. Тюлячи

КАРАР

«25» марта 2026 ел

№ 36

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 26 мартындагы 132 номерлы «Теләче муниципаль районы территориясендә ирекле төзелешне ачыклау һәм туктату эшләрен оештыру турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнарында кадрлар үзгәреше сәбәпле, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 26 мартындагы 132 номерлы «Теләче муниципаль районы территориясендә ирекле төзелешне ачыклау һәм туктату эшләрен оештыру турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- әлеге карар белән расланган Ирекле төзелешне ачыклау һәм туктату буенча район комиссиясе турында нигезләмәдә:

А) 2.1. пунктта «әлеге карарның 2.1 пунктына нигезләнеп» сүзләрен төшереп калдырырга;

Б) 4.1. пунктта «кабул итә ала» сүзләрен «кабул итә» сүзенә алыштырырга;

В) 4.3. пунктта «чакырыла алалар» сүзләрен «чакырылалар» сүзенә алыштырырга;

- күрсәтелгән карар белән расланган, Ирекле төзелешне ачыклау һәм туктату буенча район комиссиясе составын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| Низамов Б.М. | - | Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Житәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары, комиссия рәисе; |
| Гайбадуллин И.И. | | Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы, комиссия рәисе урынбасары; |
| Садыкова Г.Р. | - | Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече, комиссия секретаре. |

Комиссия әгъзалары:

Зыятдинова Р.Г. - дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Саба һәм Теләче районнары буенча муниципальара бүлеге башлыгы (килешү буенча);

Хәсәнов Б.Н. - МКУ «Теләче муниципаль районы Мөлкәт һәм жир мөнәсәбәтләре палатасы» рәисе;

Теләче муниципаль районы авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча).

- әлеге карар белән расланган Ирекле төзелешне ачыклау һәм туктату буенча район комиссиясе регламентына:

А) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Сорауны кабаттан карау буенча карар кабул итү тәртибе.»;

Б) 6.1 пунктның 1 абзацында «кабул итәргә хокукы бар» сүзләрен «кабул итәләр» сүзләренә алыштырырга;

В) 6.1 пунктның 2 абзацында «була ала» сүзләрен төшереп калдырырга;

Г) 6.2 пунктның 5 абзацында «оештырыла ала» сүзләрен «гамәлгә ашырыла» дигән сүзгә алыштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Теләче муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://tulachi.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

Житәкче И.Х. Хәмидуллин